КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 июль г.Казань № 552

2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан «Технопром-2024» технологик үсеш халыкара форумында Татарстан Республикасы делегациясе катнашуына бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Қарарга теркәлгән 2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан «Технопром-2024» технологик үсеш халыкара форумында Татарстан Республикасы делегациясе катнашуына бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 13 июль, 552 нче
карары белән расланды

2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан «Технопром-2024» технологик үсеш халыкара форумында Татарстан Республикасы делегациясе катнашуына бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм 2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан «Технопром-2024» технологик үсеш халыкара форумында Татарстан Республикасы делегациясе катнашуына бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидия, форум).

2. Субсидия бирү максаты - форумда Татарстан Республикасы делегациясе катнашындагы чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

3. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучы буларак, тиешле финанс елына субсидия алуга бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче булып «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе (алга таба - вәкаләтле орган) тора.

Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

4. Субсидия 2024 елга әлеге Тәртипнең 2 пункты белән билгеләнгән максатка вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә юридик затка бирелә.

5. Сайлап алуны үткәрү ысуллары - юридик затлар тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен җибәрелгән заявкалар нигезендә (алга таба - заявка) юридик затның әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керүнең чиратлылыгыннан чыгып, тәкъдимнәрне сорату.

6. Юридик затны сайлау критерийлары:

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясе территориясендә һәм аның территориясеннән читтә форумнар, конференцияләр, күргәзмәләр, семинарлар, шул

исәптән халыкара, оештыра һәм үткәрә, шулай ук мондый чараларны оештыруда һәм уздыруда катнаша, шул исәптән финанс ярдәме һәм башка ярдәм рәвешендә;

фәнни, фәнни-техник программаларны һәм проектларны, инновацион проектларны, шул исәптән фәнни оешмаларны һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын перспективалы үстерүгә юнәлдерелгән проектларны финанс белән тәэмин итә;

продукцияне, интеллектуаль хокукларны, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне Россия һәм чит ил базарларында чыгаруга ярдәм итә;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге турында» 2020 елның 24 февралендәге ПУ-115 номерлы Указы белән төзелгән Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәгендә катнашучы булып тора;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли.

7. Заявка бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага юридик зат туры килергә тиешле таләпләр:

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки юридик затның баш хисапчысы турында мәгълүматлар булмау;

үзгәртеп оештыру (юридик затка кушу, башка юридик зат рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентгтан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры

булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмау;

бу Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау.

8. Сайлап алуда катнашу өчен юридик зат вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

үз эченә шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә юридик зат турындагы, юридик зат бирә торган заявка турындагы мәгълүматны, тиешле сайлап алуга бәйле булган юридик зат турындагы башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын ала торган һәм бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән формада булган заявка;

юридик затны гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга кертелә торган барлык үзгәрешләр турындагы документларның күчермәләрен;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсен;

юридик зат җитәкчесе тарафыннан имзаланган, юридик затның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган гарантияле хат;

юридик затның әлеге Тәртипнең 6 пунктында санап үтелгән сайлап алу критерийларына туры килүен раслый торган документлар;

Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуын оештыруга бәйле чыгымнарның сметасы;

калькуляция, исәпләүләр кушымтасы һәм бәяләрне нигезләү белән меню (субсидия акчалары исәбеннән түләү планлаштырыла торган форумда катнашучыларны тукландыруны оештыруга тотылган очракта);

заявка бирү датасына Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуын оештыруга бәйле төзелгән килешүләр, алар буенча түләү субсидияләр акчалары исәбеннән планлаштырыла.

Әлеге пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән документлар юридик зат тарафыннан тәкъдим ителмәгән очракта, вәкаләтле орган аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Юридик зат сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән срокларда кәгазь чыганакта заявка булдыра һәм тапшыра, аңа юридик затның җитәкчесе үз кулы белән имза куя һәм вәкаләтле органга турыдан-туры яисә почта аша җибәрә.

Юридик зат тарафыннан заявканың тапшырылу датасы дип вәкаләтле орган урнашу урыны буенча аның почта бүлегенә керү датасы яисә вәкаләтле органга турыдан-туры заявка керү датасы санала.

Электрон формада файдалану мөмкинлеге булган, заявкага кертелә торган документлар һәм материаллар күчермәсендә мәгълүматны карау өчен билгеләнгән һәркем файдалана алырлык программа тәэминаты белән документны тулысынча яки аның бер өлешен карау мөмкинлеге тәэмин ителә торган, киң таралган ачык форматта булырга тиеш (кәгазь чыганакта урнаштыру чыганагына гиперсылтама күрсәтелә яисә электрон файл җайланмасы теркәлә) һәм шифрланмаган яисә махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән сакланмаган булырга тиеш.

Юридик зат заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда юридик зат заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яисә заявканы кире алу юридик зат тарафыннан әлеге Тәртиптә билгеләнгән заявканы төзүнең шундый ук тәртибендә юридик зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алу вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Заявкаларны сайлап алуны үткәрү сроклары, кабул итү сроклары, заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

Вәкаләтле орган, сайлап алу башлану датасына кадәр биш календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә юридик затларга карата таләпләр һәм юридик затлар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 8 пункты нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 11 - 13 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

юридик затларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм төгәлләнү датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

Вәкаләтле орган, табигый яисә техноген һәлакәтләр, хәрби хәрәкәтләр, вәкаләтле органнар тарафыннан гадәттән тыш дип танылган башка хәлләр белән бәйле рәвештә барлыкка килгән, җиңеп булмый торган вакыйгалар килеп чыккан очракта, сайлап алу уздырмый.

Вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуны уздырмау турында белдерүне урнаштыру заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә. Сайлап алуны уздырмау турында белдерүгә вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан кул куела, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм сайлап алуны уздырмау сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алу «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында аны гамәлдән чыгару турында игълан урнаштырылган көннән юкка чыгарылган дип санала.

Әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә сайлап алуны юкка чыгару срогы тәмамланганнан соң һәм субсидия алучы белән килешү төзелгәнче вәкаләтле орган Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны юкка чыгарырга мөмкин.

11. Вәкаләтле органга кергән заявка керү датасына һәм вакытына карап чират буенча кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка биргән юридик затның вәкаләтле вәкиленә, аны алу датасын һәм вакытын күрсәтеп, заявка алган Вәкаләтле органның вазыйфаи заты имзасы белән заявка алуда расписка бирелә.

Заявка почта элемтәсен оештыру аша кергәндә, заявканы теркәү датасы дип вәкаләтле органга почта җибәрүләрен турыдан-туры бирү белән шөгыльләнүче почта элемтәсен оештыруның структур бүлекчәсе тарафыннан почта аша җибәрү датасы һәм вакыты санала, һәм алар почта юлламасында почта элемтәсен оештыруның тиешле структур бүлекчәсе штемпеле белән расланган.

Заявкалар вәкаләтле органның урнашу урыны адресы буенча карала. Бер юридик зат бер генә заявка бирергә мөмкин.

12. Вәкаләтле орган заявкаларны карау максатларында заявкаларны карау буенча комиссия (алга таба - Комиссия) төзелә. Комиссия вәкаләтле зат хезмәткәрләре арасыннан составы кимендә биш әгъзадан (рәисне кертеп) торган итеп төзелә.

Комиссия эше утырышларда башкарыла. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия заявкаларны кабул итү срогы чыккан көннән килә торган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә:

заявкаларны кергән чираты нигезендә, шулай ук юридик затның бу Тәртипнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү-килмәвен карап тикшерә;

сайлап алуда җиңүчене билгеләү турында карар кабул итә, ул Комиссия утырышы үткәрелгән көндә беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аңа Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имза куела.

Комиссия карарлары Комиссия утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия утырышының беркетмәсе аңа имза куелган көнне вәкаләтле орган җибәрелә.

Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

юридик затның бу Тәртипнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларынга һәм таләпләренә туры килмәве;

әлеге Тәртиптә каралган сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

юридик зат тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

юридик зат тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

юридик зат тарафыннан заявканы аларны кабул итү вакыты тәмамлану датасыннан һәм (яки) вакытыннан соң бирү.

Заявка заявкаларны карау стадиясендә кире кагылган очракта, заявкаларны бирү срогы тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә вәкаләтле орган бу хакта юридик затка хәбәр җибәрә.

13. Вәкаләтле орган Комиссия беркетмәсе нигезендә субсидия бирү турында карар кабул итә һәм аны вәкаләтле орган боерыгы белән Комиссия беркетмәсенә имза салынган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча раслый.

14. Вәкаләтле орган сайлап алуда җиңүчесе билгеләгән көннең иртәгесеннән соңгы биш календарь көннән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган сайлау нәтиҗәләре турында мәгълүматны урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары каралган юридик затлар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән юридик затлар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

15. Бирелә торган субсидия күләме ($С_р$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_р = Р_1 + Р_2 + Р_3 + Р_4,$$

Р1 - коллектив шартнамә, килешүләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә торган Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуын оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары, сум;

Р2 – бу Тәртипнең 16 пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән юнәлешләр буенча смета чыгымнары вәкаләтле орган тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар, сум;

Р3 - Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуын тәэмин итүгә бәйле рәвештә исәпләнгән салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар түләүгә чыгымнар, сум;

Р4 - Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуын оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле персоналның хезмәтенә түләү буенча салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләүләр чыгымнары, сум.

16. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре:

Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуын оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле персоналның хезмәте өчен түләү;

Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуына бәйле рәвештә заявка бирү датасына төзелгән һәм (яисә) төзелергә планлаштырыла торган поставкалар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән элемтә, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр күрсәтү, мөлкәтне тоту буенча хезмәт күрсәтүләр һәм башка килешүләр буенча түләү;

Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуын тәэмин итүгә бәйле рәвештә исәпләнгән салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар түләү;

Татарстан Республикасы делегациясенең форумда катнашуын оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле персоналның хезмәте өчен түләү.

17. Субсидия алучы субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

18. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

форумда катнашу өчен Татарстан Республикасы делегациясендә катнашучылар саны - кимендә 10 кеше;

форум кысаларында урнаштырылган Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерү турында мәгълүмат материаллары булган стендлар саны - кимендә бер.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә 2024 елның 1 ноябренә кадәр ирешелергә тиеш.

19. Субсидия бирү өчен нигез – вәкаләтле орган белән субсидия алучы арасында әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан майлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән соң килә торган өч эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасы нигезендә төзелә торган килешү.

Килешүдә вәкаләтле орган һәм субсидиясе алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формалар рәвешләр нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шартлары һәм тәртибе булырга тиеш.

Килешү үз эченә субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы.

Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Вәкаләтле органга элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта килешүгә килешүнең яңа шартларын килештергәндә яисә яңа шартлар буенча килештерелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Вәкаләтле орган, кирәк булганда, субсидия алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

20. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә грант алучы үзгәртеп оештырылган очракта, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

21. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

22. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 21 пунктында каралган нигезләрдә сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарткан, сайлап алуда җиңүче килешү төзүдән баш тарткан, сайлап алуда җиңүче сайлап алуны уздыру турында игълан белән билгеләнгән срокта килешүне имзаламаган очракта вәкаләтле орган заявкасы җиңүче дип танылган юридик заттан соң икенче тәртип номеры белән булган юридик зат белән килешү төзи.

23. Сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре буенча сайлап алуда җиңүче килешү төзүдән баш тарткан, субсидия алучы белән килешүне өзелгән очракта вәкаләтле орган әлеге Тәртип нигезләмәләре нигезендә өстәмә сайлап алуны уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

24. Сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип танылa.

25. Субсидия, субсидия бирү турындагы карарны вәкаләтле орган кабул иткән көннән соң килә торган календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында субсидия алучы тарафыннан ачылган субсидия алучының исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерелә.

26. Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 көненә кадәр, шулай ук 2025 елның 15 гыйнварына кадәр, вәкаләтле органга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидиянең тиешле төре өчен билгеләнгән килешүнең бертип формалары буенча субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Вәкаләтле орган кергән хисапларны алар вәкаләтле органга кергән көннән алып бер эш көне эчендә терки. Вәкаләтле орган субсидия бирү нәтиҗәсенең әһәмиятенә ирешү турында хисапны һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисапны карый, субсидия алучының хисапларын кабул итү турында яисә субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе күрсәткеченә ирешелмәгән яисә финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашырганда хокук бозулар ачыкланган очракта субсидия

алучының хисапларын кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм субсидия алучыга аларны алган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча кабул итү (кабул итүдән баш тарту) турында хәбәр итә.

27. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше субсидия алучы тарафыннан 2025 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

28. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

29. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыручы вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Вәкаләтле орган тарафыннан нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

30. Субсидия алучы тарафыннан, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган (устав (тупланма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш), шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта субсидия алучы, шулай ук күрсәтелгән затлар алынган акчаларны вәкаләтле органның язма таләпләрен алган көннән алып 30 календарь көн эчендә тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кайтара .

31. Әлеге Тәртипнең 27, 30 пунктлары нигезендә субсидия чараларын Татарстан Республикасы бюджеты керемenә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, вәкаләтле орган субсидия алучының алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарудан баш тарту турындагы хәбәрен алган көннән яки субсидия алучы алган һәм вәкаләтле органның язма таләбендә күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле рәвештә кире кайтару вакыты чыкканнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

32. Субсидиядән нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп тору вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан «Технопром-2024» технологик үсеш халыкара форумында Татарстан Республикасы делегациясе катнашуына бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

Теркәлү саны: ____________
Заявка теркәлү датасы: ____________

2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан «Технопром-2024» технологик үсеш халыкара форумында Татарстан Республикасы делегациясе катнашуына бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирүгә сайлап алуда катнашуга
заявка

| Юридик затның исеме | Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Юридик затның урнашу урыны, телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Әлеге заявка белән юридик зат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан «Технопром-2024» технологик үсеш халыкара форумында Татарстан Республикасы делегациясе катнашуына бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 13 июль, 552 нче карары белән расланган 2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан «Технопром-2024» технологик үсеш халыкара форумында Татарстан Республикасы делегациясе катнашуына бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенең 7 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслай.

Әлеге заявка белән юридик зат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә юридик зат турында, юридик зат тарафыннан бирелә торган заявка

турындагы мәгълүматны, субсидия бирү өчен тиешле сайлап алу белән бәйле юридик зат турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслый.

Кушымталар: 1.
2.

Заявка бирүче ________________________________________________________________

(юридик зат исеме) (җитәкченең фамилиясе, инициаллары) (имза)

_________________________